# Ислам нуры

اسلام نوری

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№ 6 (682) 28 март 2019 ел (1440, Рәҗәб) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга



## Коръән бәйгесе узды



27 март көнне Чаллыда мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балаларның Татарстан республикасы күләмендәге Коръән уку бәйгесе уздырылды. Әлеге матур чара бәйге булудан битәр, бәйрәмне хәтерләтә, ул инде традицион рәвештә, шәһәребездә 24 нче тапкыр үтә. Республикүләм дисәк тә, узган ярышларда да, быел да үзләренең көчләрен сынап карарга теләүчеләр арасында күрше төбәкләрдән килүчеләр дә бар иде. Башкортостанның Илеш районыннан, Киров өлкәсеннән, Удмуртиядән килгән егетләр-кызлар ара ераклыгына да карап тормаганнар! Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт шәһәрләреннән, Сарман, Мөслим, Тукай, Әгерҗе кебек районнардан килгән балаларга да һәм аларның әти-әниләренә, мөгаллимнәренә афәрин диясе килә. “Ак мәчет”тә узган бәйгедә аларның һәрберсен җиңүче дип бәяләп булыр иде. Балаларның күбесе Коръәнне әти-әниләре ярдәмендә һәм мәчетләрдә кичке дәресләрдә укырга өйрәнгәннәр. Кызлар - аерым, малайлар - аерым, дүртәр төркемгә бүленеп көч сынаштылар. Җиде яшькә кадәрге, җидедән ун яшькә, уннан - унөч яшькә, унөчтән - унбиш яшькә кадәрге төркемнәрдә быел ике йөзгә якын бала үзләренең белемен, осталыгын күрсәтергә килгән иде. Мәчетнең имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиев аларның һәммәсенә уңышлар теләде. Хөкемдарлар - мәртәбәле хәзрәтләр - балаларның һәрберсен игътибар белән тыңлап, үз бәясен бирде. Чаллы шәһәренең имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин җиңүчеләрнең һәрберсенә матур бүләкләр, дипломнар тапшырды.

Чараның оештыручылары – Татарстан республикасы мөселманнары диния нәзарәте, Чаллы шәһәре мөхтәсибәте һәм “Ислам нуры” дини-эшмәкәрлек үзәге.

## Дин әдәпләре



Һәрнәрсәне бар иткән вә безне гүзәл сурәттә яратып, гакыл нигъмәте бүләк иткән мәрхәмәтле Аллаһы Тәгалә хәзрәтенә ихлас белән коллык итегез, ата-ана вә остазларыгыздан артык мәхәббәт белән боерыкларын җиренә җиткерергә тырышыгыз! Коллык димәктән, көнозын намаз уку вә зикер әйтү, яки барлык эшләрне бер тарафка куеп, мәчет вә тәкияләрдә яту вә яки зиратларга йөрү дип кенә аңламыйча, бәлки Аллаһы Тәгаләнең боерган юлы белән өстендә булган бурычларны үтәү, халык белән гүзәл мөгамәләдә булу, рәхмәтле вә шәфкатьле булу һәм гөнаһлардан саклану дип аңлагыз вә шулай гамәл итегез! Хөрмәтле Рәсүлулла китергән мөбарәк ислам шәригатенә үз башыгыз белән бер хәреф арттырмагыз вә бер хәреф киметмәгез; бер хәреф арттырган вә бер хәреф киметүдә булган затларга һич иярмәгез. Бәхет исә — саф шәригатьтәдер, моны һәрвакытта хәтерегездә тотыгыз! Киемнәрегезне, тәннәрегезне кер вә пычраклардан пакьләгән кебек, күңелегезне дә икейөзлелек, алдау, үч тоту, көнчелек, ачу, золым кебек бозык холыклардан пакь итегез!

***(Риза Фәхреддин, “Әхлак гыйлеме”.)***

## Халыкара конференция

16 мартта Чаллы шәһәренең “Ак мәчет” мәдрәсәсендә «Җәмгыять тормышын тотрыкландыруда ислам диненең әһәмияте» исемле IV Халыкара (Россия, Төркия, Әзербәйҗан, Казахстан, Иордания, Төркмәнстан, Италия галимнәре катнашында) фәнни-гамәли конференция булып узды. Бу конференция эшен алып баруда 20 фән докторы, профессорлар, 21 фән кандидаты, магистрлар, фәнни-тикшеренү институтларының фәнни хезмәткәрләре, мәдрәсә җитәкчеләре һәм мөгаллимнәре катнашты. Конференциядә мәгарифкә, җәмгыятьтә барган мөһим проблемаларга кагылышлы мәсьәләләр күтәрелде һәм аларны чишү юллары тикшерелде. Һәм нәтиҗәдә түбәндәге резолюция кабул ителде: 1.Төрле милләт һәм дин вәкилләре арасындагы дуслык-хезмәттәшлекне ныгыту. 2.Дин һәм фән галимнәре арасындагы хезмәттәшлекне киңәйтү. 3.”Ак мәчет” мәдрәсәсе каршында эшләп килүче “Татар ислам мәгарифе тарихы” музеен яңарту-тулыландыру эшчәнлеген дәвам итү. 4.”Җәмгыять тормышын тотрыкландыруда ислам диненең әһәмияте” дигән IV халыкара фәнни-гамәли конференция җыентыгын нәшер итү.



## Кызлар булдыра!



Чаллыда “Хәләл Фест – 2019” эшмәкәр мөслимәләр фестивале узды. Анда Казан, Әлмәт, Минзәлә, Менделеевск, Чирмешән, Тукай районы мөслимәләре катнашты. Россия һәм Татарстан мөслимәләр җәмгыяте җитәкчесе Наилә ханым Җиһаншина халыкара ислам бизнесы турында мәгълүмат бирде, “Хәят ” мөслимәләр оешмасы рәисе Рима ханым Исхакый шәһәребездә мөслимәләр өчен башкарыла торган проектлар турында сөйләде. Фестивальдә 22 бизнес-леди үз эшчәнлеге белән таныштырды. Алар арасында «Мәрхәмәтле ярдәм» гаилә кору үзәге дә, “Хәзинә” мөселман балалары клубы да бар иде. Клубның җитәкчесе Ләйсән ханым Әхмәтшина балалар клубы һәм аның каршында эшләп килүче “Асыл зат” төркеме турында бик җылы сүзләр белән телгә алды. Әлеге чараны уздыруда ярдәм күрсәтүчеләргә - Чаллы имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллинга, фестивальне оештыруда башлап йөрүче, «Асия» мөселман киемнәре кибете җитәкчесе Гөлнара Бәдретдиновга, «Мәрхәмәтле ярдәм» гаилә төзү үзәге җитәкчесе Мансур Мәхмүтов, «Хәләл-үзәк» җитәкчесе Илдар Зияров, «Челны-мясо» ҖЧҖ генераль директоры Фәндүс Хафизов, “Отис+“ мебель фабрикасы, декоратор Валентина Беликка, алардан тыш, рухи яктан ярдәм итүчеләргә дә Аллаһның рәхмәтләре булсын!




# “Аллаһы бирүчегә бирә, саранныкын тартып ала”

**Әгәр Аллаһы бер бәндәсенә мал-мөлкәт бирсә, әлбәттә, ул башкалар белән бүлешә белергә тиеш. Аллаһы бирүчегә бирә, саранныкын тартып ала. Җәмгыятьтә көчлеләрнең ярдәменә мохтаҗ кешеләр шактый. Ислам динендә ярдәмгә мохтаҗ булган катламны кайгырту һәрвакыт күз уңында булган.**

Сөбханаллаһ, шәригатьтә каралган хакларга күз салыгыз: фәкыйрь¬-мескеннәр, тол хатыннар, атасыз калган ятимнәр, юл мәшәкатенә дучар мосафирлар, бәла-казага тарыган кешеләр, залим тарафыннан кимсетелгәннәр (мәзлүмнәр), урын өстендәге хасталар, чал чәчле өлкәннәр һәм сабыйлар хакы... Болар турында галимнәр күпме китап язган, имамнар мөнбәрләрдән күпме вәгазь сөйли?! Әмма бу вәгаземдә яр¬дәмгә мохтаҗ катламның хакы түгел, киресенчә, шул мохтаҗларга ярдәм кулы сузучыларның хаклары турында сөйләргә ниятләдем. Әйдәгез, зәгыйфьләр түгел - ә көчлеләрнең, арттан ияртүчеләр түгел - башкаларны ияртеп баручыларның, өммәтне, милләтне алга тартучыларның хакларына бераз тукталып китик. Күп нәрсәне белеп торучы «Гугл»га «зәгыйфьләр, фәкыйрьләр хакы» дип кертсәң, шулкадәр күп мәгълүмат табасың. Әмма «байлар хакы», «көч-куәт ияләре хакы» дигәч, интернетта әллә ни күп нәрсәгә юлыгып булмый.

Ни өчен дини язмаларда зәгыйфь катламның хаклары турында күп языла, ә көч-куәт ияләренең хаклары бик аз искә алына? Ә бит, нәрсә булса да, шуларга чабабыз: «Зәкятеңне түләдеңме? Зәкят - һәр мөселман баена фарыз», «Әйдә, мәчет салырга ярдәм ит әле!», «Авырып ятучы кардәшебезгә ярдәм кирәк», «Бер балага операция ясатабыз», «Бер гаиләнең өе янып беткән»... Әле моныңише хәйрия эше белән хөкүмәт өлешен түләгәннән соң гына шөгыльләнеп була бит. Хө¬күмәт тә эш адәмнәрен артык иркәләми: «Декларация тутыр», «Салымыңны түлә», «Сабан туена өлеш керт», «Машинаңа күбрәк төягәнсең, ясагыңны түлә!» һ.б. Кыскасы, «Сез, эшкуарлар, безнең алда муеннан бурычлы». Монысы аңлашыла, ә без аларга нәрсә тиеш икән? Тупны бер капкага гына тибү дөрес түгел, һәрнәрсәдә гаделлек кирәк. Көч-куәт әһелләренең, өммәтебезгә хезмәт итүчеләрнең җәмгыять, халык өстендә нинди хаклары бар?

Еш кына: «Ходай каршында барысы да тигез», - дигән сүзне ишетергә туры килә. Шиксез, Аллаһы каршында, Аның шәригате каршында - кешеләр тигез. Акчасы күп яки дәрәҗәсе зур булганга карап кына, беркемнең дә өстеннән фарыз төшми, хәрәм дә хәләлгә әйләнми. Әмма һәр урында, һәр җирдә кешеләрнең барысын да бер калыпка салып тигезләү гадел булмый. Сөекле пәйгамбәребез (с.г.в.): «Кешеләргә үз урыннарын бирегез», - дигән (Әбү Даут риваяте). Динебез һәркемгә, үз дәрәҗәсенә карап, лаеклы урынын бирергә өйрәтә. Өлкән кеше белән яшь кеше, галим белән надан, тырыш белән ялкау тигез дәрәҗәдә була алмыйлар. Шуңа күрә кайбер кешеләрнең: «диндә барысы да тигез», - дигән сылтау белән хөрмәт иясен хөрмәтләмәүләре аларның наданлыгына һәм әдәпсезлегенә кайта.

«Тарихны шәхесләр ясый», - дигәннәр. Аллаһы Үзенең хикмәте белән һәр милләт, һәр халык өстеннән аларны җитәкләүчеләрне - алга этәрүче яки упкынга илтүче шәхесләрне куя. Аларга арбаны тарту өчен көч-куәт, мал-мөлкәт бирә. Бу - Аллаһы куйган тормыш кануны булып тора. Сөекле пәйгамбәребез хәтта сәфәр кылганда да арадан кемнедер җитәкче итеп куярга, аңа ияреpгә кушкан һәм: «Әгәр өч кеше сәфәргә чыксалар, арадан берсен әмир итеп сайласыннар», - дигән (Әбү Даут риваяте).

Илдә җәмгыять системасы үзгәреп, социализм килгәч, «Без бар халыкны тигезлибез!» - дип, гади халыкны өметләндерәләр. Хәзерге Сарман районының Яхшыбай авылында (бабаларым шушы авылдан) XIX гасыр азагы-XX гасыр башында авылның тоткасы булган, тирә-юньдәге мәчет-мәдрәсәләргә ярдәм итүче Мортаза Мусин яшәгән. Үзе вафат булганда, васыять итеп, дин-мәчетләр өчен 90 мең сум вакыф акчасы калдырган (Аллаһы милләттәшебездән разый булсын). Шул Мортаза хаҗи мәшһүр «Әль-Иткан» тәфсирен язган Шәйхелислам Хәмидине үз авылында имам итеп тоткан, хезмәт итү өчен аңа барлык мөмкинлекне тудырган. «Гаетләрдә ат арбасына күчтәнәчләр төяп, авыл буйлап тарата иде», - дип сөйли торган булган бабамның әнисе. Хөкүмәткә сәвит власте килгәч, шул авылның бер кешесе әйтә икән: «Бу сәвит власте халыкны тигезлибез дигәч, мин ничек Мортаза кадәр мал асрый алыйм, аның кадәр иген үстерә алыйм дип бик кайгырган идем. Безне - аларга түгел, ә аларны безгә тигезләүләрен ишеткәч тынычландым». Чыннан да, нишләптер, коммунистлар ярлыларны байларга тигезләргә ашыкмадылар. «Әйдә, туган, эшлә, тырыш, син дә бай булырсың», - дип, халыкны өскә таба тартмадылар. Киресенчә, өстәрәк булганнарны аска тартып төшерделәр һәм байларны хәерчегә әйләндерделәр. «Кулак», «халык дошманы» кебек гаеп¬ләүләр тагып, кулыннан эш килгән, көче булган, уйлый-фикерли белгән күпме кешене изделәр! Үзен һәм гаиләсен генә түгел, туган авылын, милләтен дә яшәтә алган кешеләрне юкка чыгардылар.

Аллаһы Тәгалә, Үзенең кешелеккә булган соңгы мөрәҗәгате белән, ахыр илчесен җибәргәч, аның янына җир өстендәге иң хәерле кешеләрне җыя: хатыны Хәдичәне, Әбү Бәкер, Гомәр, Госман, Гали, Гайшә һ.б. Әлеге шәхесләр пәйгамбәргә иң зур терәк булалар һәм ислам динен офык-кырларга таратуда зур өлеш кертәләр.

Бүген дә ил, милләт, халык, дин, мәгърифәт эше шундый ирләрдән һәм хатыннардан башка бара алмый. Һәр эшнең, һәр уңышның нигезендә - кемнәрнең¬дер зур хезмәте, йокы¬сыз төннәре, эчкерсез фидакарьлеге. Казан ханлыгы алынганнан соң, татар мөселман өммәте 500 ел изелеп яшәсә дә, һәр заманда милләтебезнең үзаңы, иманы өчен көрәшүче ирләр һәм хатыннар була. Узган гасыр башында гына да татар галимнәренең күпме хезмәт язганнарын күрәбез. 1905 елда бераз дин иреге бирелгәч, милләт телендә күпме китап, журнал һәм газета чыгарырга өлгергәннәр. Кемдер - зирәк акылы, үткен каләме, ә кемнәрдер хәләл акчасы белән татар халкының меңьеллык кыйбласын саклау өчен көрәшкән. Кызганыч, бүгенге көндә гади татар кешеләре түгел, хәтта дин өлкәсендә булганнарның да шактые Шиһап хәзрәтләрне, Риза казыйларны, Максуди, Хәмиди хәзрәтләрне, Галимҗан мөфтиләрне бик аз белә. Алар рухына догаларны аз кылабыз.

Галим ни эш кылыр, әгәр аның янәшәсендә мал-мөлкәт ияләре булмаса?! Карагыз, татар байлары күпме хезмәт кылганнар. Ырынбурның Каргалы авылыннан чыккан Хө¬сәеновлар 100ләп мәчет-мәдрәсә салдырганнар, татарның мәгарифен үстерү өчен көч түккәннәр. Шул ук яклардан чыккан бертуган Рәмиевләр, Казан байлары Юнысовлар, Апанаевлар һ.б... Аларның һәркайсына, гаилә әһелләренә бездән хәер-дога булсын.

Гомум милләт бурычларыннан инде үзебезнең кечкенә мәхәлләләребезгә күчсәк, дин, гыйлем, хәйрия эшендә нинди генә алга китеш булса да, аның башлангычында аерым кешеләр тора. Әлбәттә, һәркайсыбызның өстендә милләткә хезмәт итүче, өммәтне алга этәрүче көч-куәт ияләренең, мал-мөлкәт әһелләренең хаклары бар һәм аларны үтәмәү безнең тарафтан аларга карата золымлык була.

Дингә хезмәт итүче мал-мөлкәт, көч-куәт ия¬лә¬ренең берничә хакын искә алып китик.

Рәхмәтле булу. Әгәр мөселман кемгәдер изгелек кылса, ул Раб-бысының ризалыгын өмет итә, ә моның өчен үзен мактаганнарын да, рәхмәт укыганнарын да көтәргә тиеш түгел. «Изгелек ит тә суга сал», диелә мәкальдә. Әмма мөселманга кемдер изгелек кылса, аңа: «Ярый, миннән рәхмәт көтмә инде, Раббың рәхмәтен салыр әле», - дип әйтү дөрес түгел.

Пәйгамбәребез: «Кешеләргә шөкер итмәгән - Аллаһыга да шөкер итми», - дигән (Тирмизи җыентыгында). Әгәр Аллаһы бер бәндәсенәниндидер нигъмәт бирергә теләсә, ул нигъмәтнең аңа ирешү юлын сайлый, сәбәбен һәм сәбәпчесен булдыра. Сиңа Раббыңның нигъмәтен ирештерүчегә шөкер итүең Раббыңа шөкер кылуың була. Сиңа кемдер файдалы эш кылса, синең ул кешегә рәхмәтле булуың аны җибәрүче Раббыңа рәхмәтле булуыңны күрсәтә. Ул кешегә рәхмәтсез булуың Аллаһыга рәхмәтсезлегең булып чыга. Шуңа күрә Аллаһының иң бөек нигъмәте булган хак гыйлемнәрне безгә ирештерүче пәйгамбәрләргә, галимнәргә рәхмәтле булу, аларны ярату - өстебездәге бурыч. Аллаһы биргән гомер нигъмәтен тапшыруда сәбәпче булган ата-ананың ризалыгын алу да Аллаһының ризалыгын алуга сәбәп була. Хәдиснең икенче риваятендә: «Кешеләрнең Аллаһыга күбрәк шөкер иткәне - кешеләргә дә күбрәк шөкер итүче була», - дип килә (Имам Әхмәт, Табәрани риваятьләре).

Еш кына үзебезгә изгелек кылучыларның кем булуларын белмибез дә, ул хакта уйламыйбыз һәм аларга шөкер дә итмибез. Адәм баласының бәласе - кешенең йөз изгелеген дә бик тиз оныту, ә бер кимчелеге булса да, хәтердә калдыру. Тормышында бер эш тә кылмаучы гына абынмый. Нәрсәдер эшләргә тырышучылардан гаеп эзләргә, аларның гайбәтләрен сөйләргә яратабыз. Бер журналистның гел бер җитәкчене хурлап язуын күргәч, аңа шалтыратып: «Абый, ул түрәнең игелекле эшләре дә күп бит, ни өчен гел яманлап кына язасың», - дип сорадым. Ул миңа: «Хәзрәт, федераль акчага кылынган эшне изгелек дип санамыйм, ул аны болай да башкарырга тиеш», - дип, авызны ябып куйды. Әнә шулай уйлау - тәрбиясезлегебез, җәмәгать.

**Йосыф хәзрәт ДӘҮЛӘТШИН,**
**Казанның Идел буе һәм Вахитов районнары имам-мөхтәсибе, “Кабан арты” мәчете имам-хатыйбы.**

## СОРАУ-ҖАВАП

***Укучылардан килгән сорауларга шәригать белгече Рәфыйк МИННӘХМӘТОВ җавап бирә.***

**Сорау.** Элек бабайларның кайберләре сурәткә төшүне зур гөнаһ ди торганнар иде, хәзер өй тулы фотолар: никах булса да, туй, мәҗлес булса да, бәби туса да чалт та чолт сурәткә төшәбез бит. Аларны өйдә тоту дөрес микән?

**Алия, Актаныш.**

**Җавап.** Ислам дине буенча, өйдә фотосурәтләрне стенага элеп кую ярамый. Ябык җирдә, альбомнарда тотарга мөмкин. Бу мәсьәләдә төрле галимнәрдә төрлечә фикер бар, кайберләре рөхсәт итә, кайберләре исә мәкруһ дип саный.

# Мигъраҗ кичәсе

Рәҗәп аеның 26 көненнән 27 көненә каршы - Мигъраҗ кичәсе. Бу кичтә Пәйгамбәр Мөхәммәд (с.г.в.), күккә ашып, Раббыбыз Гаzзә вә Җәллә белән сөйләшкән һәм шул кичтән башлап барча мөэмин-мөселманнарга биш вакыт намаз фарыз кылынган. Мигъраҗ уразасы 100 көн ураза тотуга тиңләнә. Бөтен әмерләр (ураза, зәкәт, хаж) Җәбраил фәрештә аркылы килде, ә намазны Аллаһы Тәгалә турыдан-туры пәйгамбәргә укырга әмер итте. Бу - намазның нинди олы дәрәҗәдә булганын күрсәтә. Шуның өчен пәйгамбәр галәйһиссәләм: “Намаз - мөэминнең мигъраҗы”, - дип әйтте. Мигъраҗ - Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләгә якынаюның иң югары дәрәҗәседер. Мигъраҗ - Пәйгамбәребез (с.г.в.)нең иң зур могҗизаларының берсе. Могҗиза - пәйгамбәрлекнең шартыдыр. Аллаһы Тәгалә вә пәйгамбәрләргә ышанган кеше могҗизага да ышанадыр.

Мигъраҗ вакыйгасы шулай булган: Һиҗрәттән 19 ай элек Рәҗәб аеның 27сендә Пәйгамбәребез (с.г.в.) ястү намазыннан соң “Хәрәме Шәриф”, ягъни Кәгъбәнең Хатим дигән урынында ял итә. Шулвакыт, Аллаһы Тәгаләнең әмере илә, Җәбраил фәрештә килеп, “шәрхе садыр” итеп, ягъни Пәйгамбәребез (с.г.в.)нең күкрәк читлеген ачып, зәм-зәм суы белән юа. Аллаһы Тәгаләнең әмере илә иман вә хикмәт белән тутыра. Шуннан соң Пәйгамбәребез (с.г.в.) Бурак исемле яшен тизлегендә оча торган канатлы атка менә һәм Җәбраил галәйһиссәләм белән бергә Мәсҗиде Хәрамнан Мәсҗиде Әкъсага китерелә. Аннан Аллаһы Тәгаләнең әмере илә, күккә ашырыла. Исра һәм Мигъраҗ дәвамында Җәбраил галәйһиссәләм Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнең юлдашы була (“Исра” сүзе “төнлә сәфәр кылуны” аңлатса, “Мигъраҗ” сүзенең мәгънәсе “күктәге илаһи галәмгә ашу” дигәнне аңлата).

Бу Мигъраҗ вакытында хәтта Җәбраил галәйһиссәләмгә аяк басарга рөхсәт ителмәгән урыннарга барып җиткән Рәсүлебез (с.г.в.) күктәге сәфәрендә җәннәт вә җәһәннәм галәмәтләрен күрүгә ирешә.

## ӘДӘБИ СҮЗ

### Уч төбемдә – өмет

Каешланган күптән инде күңел  
Язмыш җилләрендә сыналып.  
Яшәп ятыш. Уч төбемдә – өмет.  
Шөкер итәм мең кат сыналып.

Фанилыкның сиратларын кичәм,  
Ачу тотмый кырыс дөньяга.  
Рәхмәт укып ихлас дога кылам,  
Йөзем төбәп көн дә кыйблага.

Ялган төсләр ялган буяуларда,  
Заман кулларында пумала.  
Боек күзләр, җансыз йөзләр аша  
Дөнья яктылыгы югала.

Бәгырьләрне телә нахак сүзләр,  
Кырау ала җылы хисләрне.  
Көндез чыра ягып эзләп йөрим  
Изгелектән калган эзләрне.

Каешланган күптән инде күңел,  
Яшьләр кипкән, ахры, күзләрдә.  
Явызлыктан түгел, яхшылыктан,  
Елыйм кайчак җылы сүзләрдән.

Бу дөньяда юкка яшәмимдер,  
Үз бәхетем, сагыш, ярам бар.  
Калебемне ачып сыенырга,  
Ышанырга газиз Аллам бар.

***Гөлүсә Батталова.***

# Кар бөртекләре

*Кара җирнең өстенә*  
*Каз мамыгы түккәннәр.*  
*Ап-ак юрган теккәннәр.*  
*Ап-ак онны сипкәннәр.*

Табышмакта халкыбыз карны каз мамыгы, ап-ак юрган һәм он белән чагыштырган. Кар һәм, гомумән, кышкы табигатьнең гүзәллеге бик күп кешеләрне сокландыра. Ул гүзәллеккә мәңге карап торсаң да, туймассың төсле. Ә ни өчен Аллаһы Тәгалә безгә шундый матур табигать күренешләре бүләк иткән соң?..Әйе, дөньяга күңел күзе белән карап, гаҗәпләнә белгән кеше генә тирән фикерле ала. Ә фикерләп яшәгән адәм баласы бар галәм һәм Җир шары Аллаһның барлыгын дәлилләүче могҗизалар белән тулганын күрә башлый, әлхәмдүлилләһ. Шулай итеп, Раббыбыз безнең белән галәм һәм табигать китабы аша да аралаша бит. Безнең җаныбызга, акылыбызга тәэсир итә. Иманыбызны уятырга һәм ныгытырга тырыша. Гаҗәеп гүзәллеккә ия булган шушы вак кына кар бөртекләреннән зур-зур кар өемнәре җыела. Кыш дәвамында миллионлаган тонна кар ява. Һәм Аллаһы Тәгалә чиксез күп кар бөртекләрен гади бер түгәрәк рәвешендә генә дә яудыра алыр иде. Ләкин Ул алай итмәгән, күп итеп бүләк итсә дә, һәрберсен, ювелир эшләгән төсле, челтәрләп, бизәкләп, искиткеч төзек һәм катлаулы формада бар иткән. Чынлап та, шаккаткыч, сүбхәнАллаһ. Аллаһ – иң гүзәл итеп Бар Итүче! Аллаһ матур һәм матурлыкны ярата.

Күктәге су парлары салкын һавада каталар да җиргә кар бөртекләре булып явалар. Ләкин бу бик озак процесс. Башта күкнең өске катламнарында бозның бик кечкенә кристалл яралгысы барлыкка килә. Аның үлчәме бер миллиметрның уннан бер өлешеннән дә кечкенәрәк. Ләкин шундый микроскопик булса да, ул инде төп-төгәл 6 почмаклы формага ия. Болыт эчендә аңа башка су кисәкчекләре ялгана башлый. Кар бөртегенең Җиргә уртача төшү тизлеге сәгатенә 900 метр дип санаганнар галимнәр. Әкрен генә үз юлын үткәндә, һәр кар бөртеге һаман-һаман ясала бара, ләкин үзенең 6 почмаклы төзелешен югалтмый.

Кызык, ә нигә 6 почмаклы микән? Һәм ничек кар бөртегенең һәр ягыннан нәкъ бертөрле катлаулы бизәкләр үсә ала? Бу Аллаһның могҗизасы! Дөньяда бер-берсенә охшаган кар бөртекләре юк, диләр. Анысын төгәл итеп Аллаһы Тәгалә генә белә. Ләкин галимнәрнең әлегә кадәр төзелеше буенча тулаем бертөсле, бизәкләренең нечкәлекләренә кадәр тәңгәл килерлек кар бөртеге тапканнары юк. 19нчы һәм 20нче гасырлар чигендә Уилсон Бентли исемле бер америка фермеры яшәгән. Һәм ул – кар бөртекләрен микроскоп аша фотога төшерүче иң беренче кеше. Бу аның яраткан шөгыле булган, ул кар бөртекләренә гашыйк булып, аларны “кар җәүһәрләре” дип йөрткән. Бентли гомере буена 5 меңнән артык кар бөртеге кристалларының фотосурәтләрен ясый алган. Һәм шул фотоларны җентекләп күзәтеп, шулай ук иң беренче булып, һәр кар бөртегенең кабатланмас, үзенчәлекле булуы турында фәнни мәкаләләр бастырган. Һәм дөнья галимнәре, ниһаять, бу могҗизага игътибар иткәннәр. Уилсон Бентлидан соң да кар бөртекләрен микроскоп аша фотога төшерүчеләр булган. Ләкин берсе дә охшашны таба алмаган. Бәлки, чыннан да, юктыр да. Мәсәлән, чагыштырыр өчен, дөньяда яшәгән миллиард-миллиард кешеләрнең дә бер-берсенә охшаш бармак эзләре юк бит! Күп булган һәм карап торышка бертөрле булып күренгән нәрсәләрнең һәрберсен үзенчәлекле итеп бар итү – Аллаһ өчен бик җиңел эш!

Кар бөртеге турында кызыклы мәгълүматлар күп. Мәсәлән, кар бөртекләре 95 процентка һавадан тора. Шуңа күрә алар бик җиңел һәм безгә ак булып күренә. Галимнәр фаразлавынча, бер кубометр карда 350 миллион кар бөртеге тупланган. Гадәттә, кар бөртекләренең диаметры 5 миллиметр. Ләкин үлчәмнәре буенча рекордсменнар да бар. Мәсәлән, 1887 елда Американың Монтана штатына диаметры 38 сантиметр булган кар бөртеге төшкән. Ә 1944 елда Мәскәүдә уч төбе кадәр (диаметры якынча 10 см булган) нык эре кар бөртекләре яуган.

Карның шыгырдавы – ул кар бөртеге кристалларының сынуыннан чыккан тавыш. Бер генә кар бөртегенең сынуын кеше ишетми, ләкин меңләгән кар бөртеге кристаллы берьюлы ватылгач, ишетелерлек шыгырдау барлыкка килә. Менә шулай, гади генә булып күренгән кар бөртеге дә үзендә күпме серләр яшергән. Аллаһы Тәгалә безгә моны, әлбәттә, фикерләр өчен бар иткән!

**Язманы “Хәзинә” клубы мөгаллимәсе Әлфия МӨДӘРИСОВА әзерләде.**

## Колак салсаң, үкенмәссең

* Әгәр малың булса, синдә аның әсәре күренсен

* Аллаһы Тәгалә юмарт. Ул юмартлыкны һәм күркәм холыкларны сөя, начар холыкларны яратмый

* Юмарт кешенең хаталарына күз йомыгыз, чөнки юмарт кешенең аягы тайса да, Аллаһы Тәгалә аңа егылырга ирек бирмәс, Аллаһы Тәгалә ул бәндәгә һәрвакыт ярдәмче була

* Тол хатын һәм мескеннәр турында кайгыртучы кеше Аллаһ юлында көрәшүчегә тиң

* Ярты хөрмәне генә булса да сәдака итеп биреп, үзегезне уттан саклагыз

* Сәдака бирү малны киметми

* Хәлле кешедән аның сәдакасын ал, син аны пакьлисең һәм аклыйсың

# Сәдаканы кемнәргә бирергә?


*(Тәүбә” сүрәсенең 60 нчы аяте)*

Сәдакалар, ягъни вәҗиб сәдака һәм зәкят фәкыйрьләргә, һичнәрсәсе булмаган мескеннәргә, әмир тарафыннан куелган зәкят җыючыларга, вә күңелләре өлфәтләндерелгән кешеләргә; янә зәкят малыннан муеннарын коллыктан азат итү өчен бирелер. Янә бурычлы кешегә аны бурычтан котылдыру өчен бирелер. Янә Аллаһы Тәгалә юлындагыларга зәкят малыннан сарыф ителер. Янә юлда акчасы бетеп, мохтаҗ булып калган юлаучыга бирелер. Шул күрсәтелгән урыннарга бирмәк Аллаһыдан фарыз ителде. Аллаһы Тәгалә сәдакага лаек булучыларны белүче, хикмәт иясе.

ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ

# “Хыялың якты булсын...”

**Игътибар итми калмагансыздыр: газетаның бу санында башкаларга изгелек эшләү, игелекле гамәлләр турында сүзебез шактый булды. Шул теманы дәвам итеп, эшмәкәр Мансур әфәнде МӘХМҮТОВ белән сөйләшәбез. Аның мәчетләргә, аерым кешеләргә күрсәткән төрле хәйриячелек гамәлләре мактауга һәм башкаларга үрнәк итеп сөйләүгә лаек. “Мәрхәмәтле ярдәм” үзәге үзе генә дә аерым бер сөйләшү таләп итә. Тик әңгәмәдәшебез үз гамәлләре турында күкрәк сугарга яратмый...**




*– Мансур әфәнде, сез “уң кулың биргәнне сулы күрмәсен” дигәнне күз уңыннан ычкындырмыйсыз инде... Алайса, гомуми сораудан - мөселман эшмәкәре дигәннән генә башлыйк әле...*

– Мөселманнар арасында эшмәкәрлекнең үсүе бик әһәмиятле мәсьәлә ул. Ни өчен дисәгез, әлхәмдүлиллаһи, бүген мөселманнар арта, мөселман гаиләләре күбәя, балалар туа. Ә менә алар өчен перспектива арта дип әйтеп булмый. Әйтик, алар өчен эш урыннары күп түгел. Төрле чак була: эшкә алганда, мәсәлән, кемнеңдер хиҗабы комачаулый, эшкә мөнәсәбәте... Башка берәү чәйнек ясый ди, подшипник ясый ди - брак китә икән, моңа күз йомарга да мөмкин. Ә мөселман кешесе хәрам ясый алмый, гөнаһ алудан курка, бу эшкә юл куймый. Мондый әйбер җитәкчегә ошамаска мөмкин, янәсе, эшне тоткарлый, керемне киметә...

Мөселманнар арасында эшмәкәрлек арту - мөселманнар өчен эш урыннары да күбәю дигән сүз ул. Сүз дә юк, мондый эшмәкәрләргә авыррак, чөнки синең конкурентларыңда шул ук товар очсызрак күренергә мөмкин. Мәсәлән, мөселман кафесында иң сыйфатлы, чиста яшелчәләрдән генә ясалган салат кайдадыр очсыз, бозыла башлаган яшелчәләрдән ясалганына караганда, әлбәттә, кыйбатрак булачак. Мөселман кешесе, табыш алам дип, спиртлы эчемлекләр дә, тәмәке дә сата алмый, үзенә гөнаһ алмый. Нәрсәгәдер күз йомарга уйласа, бөтен әҗер-савапларын, намазларын юып төшерәчәк бит. Бервакыт бер авылда кибет ачтылар, шундагы сатучы ападан сорыйм: “Нигә дип аракы, тәмәке сатасыз?” - дим. “И-и, ансыз булмый шул. Алайса, керем керми бит”, - ди...

*– Эшмәкәрлеккә тотынырга ниятләгән кешегә иң гади киңәшләр тәкъдим итәргә уйласагыз...*

– Кеше эшмәкәрлеккә тотынган икән, иң мөһиме - үзенең ни белән шөгыльләнгәнен белергә тиеш, бу шөгылен яратырга тиеш. Әгәр бизнесы куркыныч тоела икән, үз-үзенә ышанычы юк икән - тотынмавы хәерле. Эш башлаганда киләчәк турында уйларга кирәк. Алга куйган максатың, хыялың якты булырга тиеш. Мәсәлән: “Эшем алга китсә, мөселманнар өчен мәчет, мәдрәсә салдырыр идем. Кешеләргә булышыр идем. Гаилә корыр идем, балалар тәрбияләр идем...” Акча һәм табыш табыну объекты булырга тиеш түгел. Максат - дога кебек ул. Аллаһы Тәгалә синең сүзләреңне ишетә, үзе булыша. Башта якты уйлар уйлап, соңыннан акчага хирысланып алданырга гына ярамый.

Эшне артык зурга тотынудан башларга кирәкми. Кайберәүләр, мәсәлән, укып бетерә дә, алсу күзлекне салырга онытып, зур-зур кредитлар алып (монысы үзе ук гөнаһ), эш ачып җибәрә, аннан шунда батып та кала. Эшне нәфес колы булмыйча, аздан башларга киңәш итәм. Тормыш тәҗрибәсе туплый-туплый, әкрен генә алга барасың ул.

*– Сезнең хәйриячелек гамәлләренә кыскача гына тукталa алабызмы? Фәлсәфи рәвештәрәк сорасам, башкаларга игелек кылу сезгә нәрсә бирә?*

– Мин үзем эшләгән эшләр турында сөйләргә яратмыйм, әҗер-савапларымны саклыйсым килә. Шуны гына әйтә алам: берәр яхшы эш эшләсәм, көзге алдына басып, үз-үземә елмаям. “Мин бит үз нәфесемне җиңдем”, - дип сөенәм. Мин кемгәдер яхшылык эшлим - алар шатланалар. Ул куанычны күреп, мин үзем шатланам - беләсезме, бу гаҗәеп тойгы...

*– Шулай да, бүтәннәр колагына үрнәк, гыйбрәт булсын өчен, гади генә берәр тормыш вакыйгасына тукталып китсәгез иде.*

– Бервакыт җәяү генә чыгып киттем, тукталышка килеп бастым. Күрәм – янымда гына бер әби басып тора. Учларына салган тиеннәрне саный да, тагын, тагын саный... Түзмәдем, сорап куйдым: “Әби, әллә ипигә-мазар җитмиме?” - дим. Ул җавап биреп тормады. Күзен генә күтәреп карады да янә шул тиеннәрне санарга тотынды. Кесәмнән биш йөз сум алдым да әбигә тоттырдым. Шунда күтәрелеп караган мәлендә әбинең күзләрендәге аптырауны, тагын әллә нинди тойгыларны күрсәгез сез... Әлеге караштан түзмәдем мин, автобус килеп туктаган иде, үземә кирәклесе булмаса да, тиз генә утырдым да киттем... Автобуста барам. Шул мәлдә әбигә биш йөз сум биргәнемә үкенеп... “Эх, минем бит кесәмдә биш мең сумым бар иде. Нишләп әбигә бирмәдем аны?” - дигән үкенү иде ул...

*Әңгәмәдәш - Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА.*

## Көрәш

Адәм баласының бөтен гомере — акыл белән нәфес көрәше. Гомерең хаталар һәм ялгышлар җыентыгына әйләнмәсен дисәң, акылыңны намаз белән, нәфесеңне ураза белән тәрбиялә. Акылың да, нәфесең дә тәртипсез икән, беркем дә, бернинди оешма да синнән тәртипле кеше ясый алмый инде. Димәк, җәмгыятьтә дә тәртип була алмый, чөнки күп вакыт үзләре дә шул нәфес коллары булып кала бирәләр. Без кешечә яшәсен өчен Аллаһ Раббыбыз дин биргән, Коръән иңдергән, үзенең пәйгамбәрләрен җибәргән. Гомеребез, бәйрәмнәребез, яшәешебез хәрәмнәрсез, Аллаһ риза булырлык итеп үтәргә тиеш.

**Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ,**
**Татарстанның баш казые.**

## Яңа китаплар




“Ислам нуры” дини-эшмәкәрлек үзәгендә яңадан-яңа китаплар дөнья күреп тора. Эчтәлекле, мәгънәле, сыйфатлы басмалар һәр мөселманның, гомумән, һәркемнең өстәл китабы була ала. “Коръәннән догалар. Молитвы из Корана” - татар һәм рус телләрендә булуы белән үзенчәлекле. Әлеге китапны “Ислам нуры” дини-эшмәкәрлек үзәгеннән, аның кибетеннән алырга мөмкин. Чаллы шәһәре, ГЭС бистәсе, Үзәк урамы, 72 нче йорт.

<u>**Саулыгым – байлыгым**</u>

## Лимон

Лимон - судан һәм лимон кислотасыннан тора. Аның составында С, А, В1, В2, Д, витаминнары, цитрусларда гына була торган Р витамины яки цитрин бар. Лимон күп авыруларны дәвалаучы һәм косметик чара булып санала. Ангина вакытында телемләп киселгән лимонны авызга кабып суырасың һәм йотасың, моны сәгать саен кабатларга. Бигрәк тә лимонның кабыгы файдалы. Ютәлләгәндә тигез күләмдә бал, лимон согы, шикәр комы алып кайнатасың, 1аш кашыгы күләмендә кабасың. Томау төшкәндә борынга көнгә 5-6 тапкыр берничә тамчы лимон согы тамызасың. Вирусларга каршы чөгендер һәм лимон согы кушылмасы — иң яхшы чара. Гипертониядән интегүчеләргә тәүлеккә 3-4 тапкыр кабыгы белән ярты лимон ашау файдалы. Баш авыртканда лимон кабыгының ак элпәсен чистартасың һәм юеш ягы белән чигәгә куеп, берникадәр вакыт тотасың. Озакламый лимон кызарып чыгар, ә баш авыртуы бетәр. Күңел болганганда лимонның кабыгы белән йомшагы арасындагы ак элпә ярдәмгә килә. Ишетүне яхшырту өчен көнгә 1/4 лимоның кабыгын ашау да җитә. Көзән җыерганда 10 көн дәвамында иртә-кич аяк табанын лимон согы белән ышкыйсың. Сок кипкәч, оек киясең.

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**
**Баш мөхәррир**
**Айгөл Абдуллина**
**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы: 1430**
**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**28 март 16 сәг.**
**фактта 28 март 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**